# Ф.К. САГДЕЕВА, Д.Р. ГАЙНАНОВА. ТАТАРСКИЙ КОНЦЕПТ КАК ОБЪЕКТ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКОГО АНАЛИЗА

«Лингвокультурологик анализ объекты буларак татар концепты» («Татарский концепт как объект лингвокультурологического анализа». Казань, 2017. 248 с.) монографиясе 2017 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында нәшер ителде. Хезмәтнең авторлары – Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты гомуми тел белеме бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Ф.К. Сәгъдиева һәм Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының чит телләр кафедрасы өлкән укытучысы, филология фәннәре кандидаты Д.Р. Гайнанова. Фәнни редакторы – филология фәннәре докторы, профессор, академик М.З. Зәкиев, рецензентлары – филология фәннәре докторы, профессор И.Б. Бәширова, филология фәннәре докторы, профессор Л.К. Бәйрәмова.

Монографиянең исеменнән аңлашылганча, ул тел белеменең актуаль юнәлешләреннән саналган лингвокультурология мәсьәләләренә һәм аның төп категорияләренең берсе – концептның эчтәлеген ачуга багышлана. Бүгенге көндә әлеге терминнар татар филологлары тарафыннан да еш кабатлана, әмма аларның нәрсә аңлатуын без яхшы беләбез дип әйтә алмыйбыз. Хәзерге вакытта бу юнәлештә күп хезмәтләр язылa, аерым мәктәп оешты дип әйтелә. Шуңа да карамастан, лингвокультурологиянең метод-методологиясе, терминнары, аның өйрәнү объекты тулысынча өйрәнелгән дип әйтеп булмый.

Китапны укып чыккач, аның авторлары куелган максатларына ирешкәннәр дигән тәэсир кала. Биредә лингвокультурология, концепт төшенчәләре җентекләп аңлатыла. Эш барышында билгеле бер система сакланып, күп кенә фәнни хезмәтләргә анализ ясала, аларга карата тәнкыйди фикер белдерелә, күпсанлы терминнар җентекләп аңлатыла, әлеге өлкәдәге яңалыклар күрсәтеп барыла.

Аерым алганда, монографиядә тема итеп алынган проблеманың куелышы һәм чишелеше аерым бер парадигма итеп каралырга тиеш, дигән фикер алга сөрелә. Мәгълүм булганча, хәзерге лингвистикада фәнни концепцияләр бер-берсен тулыландырып торучы өч парадигманы хасил итәләр: 1) чагыштырмалы-тарихи, 2) таксономик (системалы-структур), 3) антропоцентристик (когнитив). Бүгенгә кадәр татар тел белемендә фәнни тикшеренүләр чагыштырмалы-тарихи һәм системалы-структур планда алып барылды. Хәзер исә когнитив юнәлешкә күчеш бара. Монографиядә, иң беренче чиратта, нәкъ менә әлеге моментка игътибар бирелә һәм «концепт» дигән күренеш әлеге парадигма кысаларында аңлатыла.

Бүгенге көндә «Нәрсә ул концепт?» дигән сорауга галимнәр төрлечә җавап бирә: һәр телдә стандарт, гомуммәгълүм концептлар бар, концепт ул – төшенчә, концепт ул – лексема, концепт ул – символ һ.б. Монография авторлары, әлеге мәсьәләнең төрле телләрдә ничек тикшерелүен өйрәнгәннән соң, түбәндәге нәтиҗәгә киләләр: «...вопрос об изученности концептов до сих пор остается нерешенным, что в свою очередь обуславливает актуальность данного направления в лингвистике» (б. 9) һәм алга таба татар теле материалында «Акча» концептының өйрәнелешен тәкъдим итәләр.

Хезмәттә концептларны өйрәнүнең фәнни нигезләре «Теоретические аспекты исследования» дигән беренче бүлекнең «Концепт как проблема лингвокультурологии» һәм «Лингвокультурологическая модель концепта» исемле ике бүлекчәсендә җентекләп анализлана. Аларга кадәрге өч бүлекчәдә лингвокультурология фәненең фәнни аппараты, эчтәлеге, терминнары ачыклана, кешеләрнең әйләнә-тирә чынбарлыкны танып белүдәге тәҗрибәсен концептуальләштерүнең лингвокультурологик проблемалары күрсәтелә, аларның төрле авторлар тарафыннан ничек хәл ителүе ачыла. Биредә төрле хезмәтләрдә әйтелгән фикерләр дә тиешле урынында күрсәтелә бара. Мәсәлән, шәхеснең дөньяны танып белүен – дөньяны күзаллау системасын билгеләүдә милли тел картинасының шул телдә чагылыш табуы, яисә «Владение языком, предполагает владение концептуализацией мира, отраженным данным языком» һәм «Язык выступает как способ создания и преобразования мысли» дигән фикерләрнең мөһимлегеассызыклана, ягъни адәм баласының дөньяны кабул итүе, хәтерендә калдыруы аның туган теле аша тормышка ашырыла. Нәкъ менә әлеге мәсьәләләр лингвокультурология фәненең теоретик нигезен тәшкил итәләр. Бу юнәлештә тел гомумкогнитив механизм буларак карала. Культурологик концептлар – әйләнәтирә дөнья күренешләрен концептуальләштерү нәтиҗәсендә барлыкка киләләр, һәм ул тел берәмлекләренең мәгънә компонентларында чагылыш таба. Нәкъ менә шул нигездә фикер һәм тел күренешләре, телне өйрәнә торган фәнни тармаклар үзара бергәләшә һәм керешеп китә. Аерым алганда, лингвокультурологиягә караган тикшеренүләр тел һәм культура, аларның кулланылышы һәм өйрәнелеше системасы биргегенә таянып башкарыла. Болар үзләре кеше феноменына, аның аң-фикерләренә, чынбарлыкны ничек күрүенә, инанушануларына һәм әйтеп бирү үзенчәлекләренә нигезләнә. Әлеге юнәлештә, язма текстларның телен өйрәнгәндә «тел шәхесе» (языковая личность) һәм «автор образы» (образ автора) дигән төшенчәләр файдаланыла. Димәк, лингвокультурология фәне үз эченә тел белеменең әдәби әсәрләр телен өйрәнә торган тармагы терминнарын да ала, аларны үзенә кирәк булганча тулыландыра. Үз чиратында, «тел шәхесе»

(языковая личность) дигәндә, автор әдәби әсәр кысаларындагы теге яки бу күренешне тасвирлаганда, тел берәмлекләрен файдалану үзенчәлекләре белән бергә, аның когнитив лингвистикага караган төшенчәләрен, идеяләрен күздә тотып, дөньяны күзаллау системасын, чынбарлыкны ни рәвешле аңлавын да игътибарга алырга тиеш була.

Алга таба лингвокультурологик тикшеренүләрдә милли һәм мәдәни яссылыкка караган факторларның әһәмияте ассызыклана. Нәкъ менә әлеге күренешләр концептның нигезен тәшкил итәләр дә инде. Хезмәттә концептлар ике төргә бүлеп карала: универсаль (фәлсәфи) һәм милли мәдәният категорияләре (мәдәни концептлар). Авторлар фикеренчә, мәдәни концептлар, халыкның аңында урын алган күзаллаулар һәм стереотипларга нигезләнеп, телдә сүзләр, фразеологик берәмлекләр һәм паремияләр ярдәмендә чагылыш табалар. Биредә алар фәнни кулланылышка тел белән мәдәниятне үзара бәйләп торучы ачкыч сүз (ключевое слово) төшенчәсен кертеп җибәрәләр.

Йомгаклап әйткәндә, хезмәттә фәнни чыганакларга анализ ясау нәтиҗәсендә лингвистика өлкәсенең эчтәлеген ачыклаган төп лингвокультурологик төшенчәләр һәм атамалар билгеләнеп, аларның эчтәлеге ачылган. Бу алар арасындагы иерархик бәйлелекне, үзара бәйләнешләрне билгеләргә мөмкинлек биргән. Нәтиҗәдә лингвокультурология фәне, аның фәнни аппараты, эчтәлеге, методологиясе ачыклана, татар теле материалында концептка анализ ясауның үрнәге күрсәтелә («Акча» концепты мисалында). Шуның белән бергә, әдәби язма истәлекләрнең телен өйрәнүче белгеч буларак, кайбер фикерләргә ачыклык кертү кирәк дип саныйбыз. Концептның лингвокультурологик моделе анализланганда аң-фикерләү, мәдәният өлкәләренә күбрәк игътибар ителеп, тел ягы читтәрәк кала кебек. Ул беренче бүлекнең алтынчы бүлекчәсендә урын ала һәм биредә сүзнең мәгънәсе турында гына сүз бара. Шуның белән бергә, хәзерге вакытта сүзнең мәгънәсе, аның типлары җитәрлек дәрәҗәдә аңлатылып бетмәгән дигән фикер дә әйтелә. Нәкъ менә әлеге мәсьәлә ачыклык кертүне сорый да инде. Лингвокультурология фәне яссылыгыннан караганда, ул, мөгаен, шулайдыр, әмма сүзнең, тел берәмлеге буларак, мәгънәсе һәм аның типлары хәзерге фән таләпләренә таянып, гомуми тел гыйлемендә яктыртылганча, бик җентекләп, объектив нигездә аңлатыла һәм ул чынбарлыкка туры килә дип санала.

***Бәширова Илида Басыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми тел белеме бүлеге баш фәнни хезмәткәре*